# ТАТАРЧА–РУСЧА–ЛАТИНЧА ҮСЕМЛЕК АТАМАЛАРЫ СҮЗЛЕГЕ

# ТАТАРСКО–РУССКО –ЛАТИНСКИЙ СЛОВАРЬ НАЗВАНИЙ РАСТЕНИЙ

**УДК 943.21:82:71/73 (038) +582:001.4**
**ББК 81.2-4+28.59 ая**

Печатается по решению Ученого совета Института языка,
литературы и искусства им. Г.Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан

Книга издается на средства, выделенные на реализацию Закона Республики Татарстан
«О языках народов Республики Татарстан»

Автор-составитель:
**Г.Г.Саберова**

*Ответственный редактор* — чл.-корр.АНТ, доктор филологических наук **Ф.А.Ганиев**

*Рецензенты:*
доктор филологических наук, профессор **Ф.С.Хакимзянов** (КГГИ);
кандидат филологических наук **А.Р.Рахимова** (КГУ)

**Саберова Г.Г.**
С12 Татарско-русско-латинский словарь названий растений. — Казань: Фикер , 2002. — 96 с. с илл.

Настоящее издание первый опыт создания татарско-русско-латинского словаря по названиям растений.

Словарь охватывает более 1700 терминов и названий растений, которые широко распространены на территории Среднего Поволжья, особенно — в Татарстане. Некоторые научные наименования растений дополняются их народными названиями, что значительно облегчает пользование настоящим словарем.

Словарь предназначен для учителей и учащихся средней школы, преподавателей и студентов вузов и техникумов, переводчиков, работников печати, радио и телевидения, а также для широкого круга читателей.

**ISBN 5—93091—026—X**

© Саберова Г.Г., 2002
© «Фикер», 2002
© ИЯЛИ им.Г.Ибрагимова, 2002

## АВТОРДАН

Телләр турындагы дәүләт программасын тормышка ашыруда халык хуҗалыгы, мәдәният, фән-техника тармаклары буенча терминологик сүзлекләр төзеп кулланышка кертү беренче чиратта әһәмиятле эш булып тора. Озак еллар дәвамында милли телләрнең гамәли кулланыш даирәсе тар булуы сәбәпле, милли телдә терминологияне туплау, яңа терминнар белән тулыландыру ихтыяҗы булмады. Милли телдәге күп кенә атамалар кулланыштан чыгып онытылып беттеләр. Терминологик сүзлекләр шушы атамаларны туплап җыю, терминнар ясалышында яңа модельләр тәкъдим итү һәм аларны халыкка кайтару бурычын үтиләр.

Тел галимнәре һәм ботаника белгечләре күптәннән бирле үсемлекләрнең латин теленә таянган татарча атамаларының фәнни системасын булдырырга кирәк дип әйтеп киләләр. Фәндә Карл Линнейның бинар номенклатурасы кабул ителгәннән соң узган 250 ел дәвамында үсемлекләр терминологиясен һәм классификациясен төзүдә барлык мөстәкыйль фәннәр гигант үсешкә ирештеләр. Ә безнең татар теле исә, киресенчә, фәнни кулланыш җитмәү сәбәпле, бу өлкәдә артта кала бара. Шул нисбәттән, татарча-русча-латинча үсемлек атамалары сүзлекчәсенең кирәклеге үзен күптәннән сиздереп тора. Бу бушлыкны ниндидер күләмдә сезнең кулдагы шушы сүзлек тутыра алса, бик яхшы булыр иде. Укучыларга тәкъдим ителә торган өч телле сүзлек бу юнәлештә беренче адым булып тора.

Сүзлекнең нигезе, башлыча Казан дәүләт университеты тарафыннан чыгарылган “Определитель растений Татарской АССР” (Казань, Изд-во КГУ, 1979) белешмә сүзлегенә, төрле елларда басылып чыккан ике телле русча-татарча, татарча-русча һәм шул өлкәгә караган терминологик сүзлекләргә таянып эшләнде. Сүзлек 1700 дән артык булган термин һәм атамаларны эченә ала. Сүзлектә Урта Идел буе, бигрәк тә Татарстан җирендә үсә торган үсемлек атамаларына игътибар ителде.

Сүзлектән файдалануны җиңеләйтү өчен, күпчелек фәнни атамаларның халык телендә киң таралыш тапкан исемнәре дә китерелде.

Татарча сүз берәмлекләре әлифба-оя системасы рәвешендә урнаштырылды, ягъни башта әлифба тәртибендә берничә сүздән торган терминның төп сүзе китерелде. Ике яки берничә сүз тезмәсеннән гыйбарәт булган берәмлекләрдә төп сүз алфавит тәртибендә баш килештәге исем белән күрсәтелде.

Омонимнар күпчелек очракта аерым абзац итеп бирелде һәм бер-берсеннән рим цифрлары белән аерып күрсәтелде.

Сүзлекнең ахырында татар телендә алфавит күрсәткече һәм татар халкының үсемлекләргә бәйләнешле мәкаль һәм әйтемнәре урнаштырылды.

Бу хезмәт татарча-русча-латинча үсемлек атамалары сүзлеге төзүнең беренче тәҗрибәсе һәм ул киләчәктә төзеләчәк аңлатмалы яисә тәрҗемәле тулы үсемлек атамалары сүзлекләре өчен башлангыч мәгълүмат бирә торган нигез булыр дип ышанабыз. Автор, сүзлене кулланучылардан, аңа карата булган барлык фикерләрне, төзәтмәләрне һәм өстәмәләрне түбәндәге адрес буенча җибәрүне үтенә: 420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 2/31, Татарстан Фәннәр академиясе Г.Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты.

## ОТ АВТОРА

В свете решения государственной программы о языках и претворения ее в жизнь большую роль играет составление терминологических словарей по народному хозяйству, культуре, науке и технике.

В течение долгого времени рамки практического применения национальных языков были ограничены, поэтому сбор материалов по терминологии на национальном языке, обогащение его новыи терминами было ограничено.

Терминологические словари ставят своей целью сбор материала, предложение новых моделей словообразования терминов и возвращение их народу.

Ученые языковеды и ботаники, давно высказывали мнение о том, что нужна научная система татарских названий растений, основанная на латинских определениях.

Давно возникла необходимость выпуска татарско-русско-латинских словарей названий растений. Было бы прекрасно, если бы эти пробелы в какой-то мере смог восполнить словарь, который вы, уважаемые читатели, держите в руках.

Источником для словаря послужило справочное пособие, составленное сотрудниками кафедры ботаники Казанского государственного университета ("Определитель растений Татарской АССР", Казань: изд-во КГУ, 1979), а также в основу словаря легли двуязычные и терминологические словари, выпущенные в разные годы.

Данный словарь охватывает более 1700 терминов и названий растений, которые широко распространены на территории Среднего Поволжья, особенно — в Татарстане.

Некоторые научные наименования растений дополняются их народными названиями, что значительно облегчает пользование настоящим словарем.

Татарские словарные единицы в словаре располагаются по словарно-гнездовой системе, то есть в алфавитном порядке приводится ключевое слово термина. В составных словарных единицах ключевое слово

представлено существительным в именительном падеже. Многие термины и названия сопровождаются указанием семейств, к которым эти растения принадлежат.

Омонимы (т.е. слова с одинаковым звучанием, но разные по значению) даются отдельными абзацами и обозначаются светлыми римскими цифрами.

В конце словаря помещены: алфавитный указатель на татарском языке; пословицы и поговорки, связанные с растительным миром, а также представлен иллюстративный материал с изображением некоторых растений.

Настоящее издание — первый опыт создания татарско-русско-латинского словаря названий растений. Все замечания и пожелания будут приняты во внимание с большой благодарностью. Просим направлять их по адресу:

420111, г. Казань, ул. Лобачевского, 2/31, Институт языка, литературы и искусства им.Г.Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан.

# КЕРЕШ

Татарстан флорасы, ягъни үсемлекләр дөньясының төр составы шактый бай. Ул үз эченә 1300 дән артык үсемлекне ала. Без бу кадәр бай үсемлекләрне яхшы беләбезме, телебездә үсемлек атамаларына бәйләнешле нинди үзенчәлекләр бар соң?

Латин телендә мондый бер гыйбарә бар: "Әйберләрнең исемнәрен белмәсәң, тора-бара алар үзләре дә онытылып, юкка чыгачаклар" ("Nomina si nectis perit et cognito").

Татарның энциклопедик галиме Каюм Насыйриның үсемлекләр дөньясына караган "Гөлзар вә чәманзар" ("Үләнлек вә чәчәклек", 1894) хезмәтендә, мондый юллар китерелгән: "... безгә иң элек үз җиребездә булган үләннәрнең тамырларын, кабыкларын, чәчәкләрен һәм яфракларын яхшы тикшереп, һәр үләннең хасыятен, аның файдалымы, зарарлымы икәнлеген белергә кирәк". Галимнең моннан бер гасыр элек әйткән сүзләре ботаника фәне белгечләренә генә карамый, әлбәттә.

Карл Линнейның фәнни номенклатурасы кабул ителгәнче, һәрбер галим үзенең ачышын, ягъни үзе тапкан үсемлекне ничек теләсә шулай атаган. Еш кына галимнәр бер үк үсемлек турында сүз алып барсалар да бер-берсен аңлый алмаганнар. Аларны бутамас өчен, галимнәр үсемлекләрнең фәнни атамаларын кертkәннәр, бу фәнни атамалар бөтендөнья ботаникларына да яхшы аңлашылган. Алга таба үсемлекләрнең күптөрлелеген тәртипкә салу максатыннан чыгып, галимнәр барлык төр үсемлекләрне төркемнәргә - классларга, семьялыкларга, ыругларга, төрләргә бүлгәннәр. Үсемлекләрнең мондый төркемнәрен билгеләү өчен, аларның үзара ырудашлык дәрәҗәсен ачыклый алырлык охшаш һәм аермалы якларын нигез итеп алганнар. Төзелешләре ягыннан бер-берсенә якын торган төрләрне ыругларга берләштергәннәр. Мәсәлән, *шәфтәлу яфраклы кыңгырау чәчәк* "колокольчик персиколистный" (Campanula persicifolia) белән *кычыткан яфраклы кыңгырау чәчәк* "колокольчик крапиволистный" (Campanula trachelium) үсемлекләре икесе бер ыругка - *кыңгырау чәчәклеләр* ыругына керәләр.

Якын ыруглар үзләре бер семьялык составына керә. Мәсәлән, *бодай* ыругы *арыш, арпа* һәм башка күп кенә аларга ыругдаш ыруглар бер зур семьялык - кыяклыклар семьялыгын тәшкил итәләр. Семьялыкларның һәркайсын үсемлекләрнең кайсы да булса бер классына кертергә була. Әгәр тикшереп карасак, классларның һәм семьялыкларның фәнни атамалары, без һәркөн диярлек ишетеп торган үсемлек атамаларыннан шактый нык аерылып торганын күрәбез. Ә инде төрләргә килгәндә, алар хәзерге телдә кулланылышта йөргән үсемлек атамаларына бик охшашлар. *Каен* агачының исемен ыруг дип алсак, аның *ак каен* "береза белая", *кәрлә каен* "береза карликовая", *таш каен* "береза каменная" кебек атамалары каенның төрләре булалар. Бу төр үсемлек атамалары гадәттә бинар номенклатура белән биреләләр. Аларда төп мәгънә ыруг төшенчәсенә – икенче компонентка туры килә, ә беренче компонент төрне билгеләү өчен хезмәт итә.

Телдә атамалар (номеннар, номенклатура) дип йөртелгән лексик катлам бар. Болар – фәннең берәр терминологик системасында күренеш, предметларга бирелгән исемнәр, атамалар. Мәгълүм булганча, исем ул – билгеле бер затны яхшы белү, тану өчен, шул затка тагылган сүзнең билгесе. Терминнардан аермалы буларак, атамалар предметны төшенчә җирлегендә түгел, ә ничек кабул ителүе, саклануы нигезендә чагылдыралар. Төрле үсемлекләрнең татар телендә йөри торган исемнәре атама (номен) дип каралалар. Бу атамаларның берсе, гадәттә, термин дип табыла һәм фәнни төшенчәгә беркетелә, башкалары гади сүз-атама гына булып калалар. Термин-атама белән сүз-атама күп вакытта телдә параллель (синоним) кулланылалар. Боларның кайсысын телдә термин итеп алу уңышлырак булыр дигән мәсьәләне хәл итү белгечләрнең һәм профессия ияләренең уртак бурычы булып тора.

Телебездә еш кына бер үк үсемлек төрле җирдә төрлечә аталып йөртелә. Моның сәбәпләре нәрсәдә соң? Бу күп кенә лингвистик һәм экстралингвистик факторларга бәйле. Шуларның берсе – үсемлекне характерлый торган билгеләрнең (без аларны тел белемендә мотивемалар дип атыйбыз) күп булуында. Берәүләр аның бер билгесен, икенчеләре икенче билгесен күреп ала, һәм нәтиҗәдә, бер үк үсемлеккә берничә атама бирелә һәм үсемлек телдә берничә исем белән аталып йөртелә башлый. Үсемлекне атау өчен, аның башта төп билгесе нигез итеп алына. Әйтик, *тидермәс* "недотрога" дип йөртелгән үсемлекне әйтү белән, аның исеменнән

күренгәнчә, бик нәфис һәм үзенә кагылганны яратмавын күз алдына китерәбез. Яки русча “*подорожник*“ үсемлеге, үскән җиренә карап, *юл яфрагы* дип аталса, яфракларының формасы һәм дымлы урыннарда үсүенә карап, бака яфрагы, дару үләне буларак *яра яфрагы* дип атала. Мондый мисалларны күпләп китерергә мөмкин. Татар телендә аерым үсемлек атамаларының вариантлары 15-20 гә кадәр һәм аннан да артып китә. *Гөлҗимеш, дүңгәләк, клевер, тубылгы* үсемлекләре шундыйлар рәтенә керәләр. Үсемлек табигатьтә никадәр еш рак очраса һәм кешегә файдалы яклары күбрәк булса, ул үсемлек синонимнарга да шулкадәр бай була.

Кайбер үсемлекләр вегетацион үсеше чорына карап, төрлечә аталып йөртеләләр. Мәсәлән, бер төрле үсемлек язын бер төрле исем астында йөрсә, көз көнендә ул икенче төрле аталып йөртелә. Моның ачык мисалы итеп, *тигәнәк* үсемлеген китереп була. Язын киң салынкы яфраклы үсемлеккә *әрекмән* “лопух“ дип әйтсәк, көзен, чәнечкеле сырышучан орлыклары өлгергәч, аны тигәнәк “*репейник*“ дип атап йөртәләр.

Татар телендә кайбер үсемлекләр һәм аларның җиләк-җимеше бер үк исемдә аталып йөртеләләр. Әйтик, *карлыган* дип без куакта үсә торган кара, кызыл һәм башка төсләрдәге әчкелтем, сусыл җимешләргә әйтәбез, һәм ул җимеш үскән куакны да *карлыган* дип атыйбыз. Мондый үсемлекләр телебездә шактый. Аларга без *алма, груша, ананас, мандарин, борлегән, дуләнә, чикләвек, шомырт, миләш, чия, хормә;* иген культураларынан – *арыш, тары, бодай, борчак, карабодай*; яшелчәләрдән – *кәбестә, кыяр, чөгендер, помидор*; җиләкләрнең бездә үсә торган төрләреннән: *кура җиләге, каен җиләге, җир җиләге, мүк җиләге, нарат җиләге* һ.б. керәләр.

Кыскасы, үсемлек атамалары гасырлар буе җыйналып килеп, телебездә булган лексик байлыкның шактый өлешен тәшкил итәләр. Аларның һәркайсының мәгънә аерымлыкларын, үзенчәлекләрен таный һәм аера белү, ботаниклар өчен дә, лингвистлар өчен дә кирәкле эш булып тора.

# ЭЧТӘЛЕК


АВТОРДАН ........................................ 3
ОТ АВТОРА ........................................ 5
КЕРЕШ ........................................ 7
ҮСЕМЛЕК ТЕРМИННАРЫ (ТАТАР, РУС ҺӘМ ЛАТИН ТЕЛЛӘРЕНДӘ) ........................................ 10
ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ҮСЕМЛЕКЛӘРГӘ БӘЙЛӘНЕШЛЕ МӘКАЛЬ ҺӘМ ӘЙТЕМНӘР ........................................ 70
ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ТЕРМИННАР КҮРСӘТКЕЧЕ ........................................ 75
КУШЫМТЫЛАР ........................................ 83
КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ ........................................ 94

**Гульзада Гарафутдиновна Саберова**

# ТАТАРСКО-РУССКО-ЛАТИНСКИЙ СЛОВАРЬ НАЗВАНИЙ РАСТЕНИЙ

Редактор: Л.Д.Халиуллина
Технический редактор: Л.Н.Дубкова

Лицензия ПД № 7-0215 от 01.11.2001 г.
Сдано в набор 16.05.02 г. Подписано в печать 05.06.02 г.
Гарнитура Таймс. Печать офсетная.
Формат 60x84 1/16. Печ. л. 6,0. Тираж 300 экз. Заказ № К-84
Министерство образования РТ
Редакционно-издательский центр «Школа».
420111, Казань, ул. Дзержинского, 3. Тел. 92-24-76.